ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ СОВЕТЫ

КАРАР № 17

Урыссу ш. т. п. "15" 08 2023 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 2022 елның 23 сентябрендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы
Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 2022 елның 23 сентябрендәге №13 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 статьясындагы 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, аның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көн булып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советына әлеге гариза керү көне тора.».

1.2. Нигезләмәнең 18 статьясындагы 1 пункты, б пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) алдан хәбәр итү тәртибендә, Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә, коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси партия, профсоюз оешмасы органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында оештырылган беренчел профсоюз оешмасының сайлап куелган органы, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, ширкәтнең

съездында (конференциясендә) яки гомуми җыелышында катнашудан тыш көчемсез милек хуҗалары)»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы Рәисе,
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы
Башлыгы А.Ә.Шәфигуллин